МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.02.2021 г.Казань № 102

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 16 гыйнварендә 7592 номеры белән теркәлде

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2021 елның 24 февралендә 102 номерлы боерыгы белән расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Бөек Ватан сугышы ветераны» таныклыгын (таныклык дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2012 елның 05 июлендәге 514 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 06.06.2014 №309, 22.06.2015 №425, 07.06.2016 №317, 08.06.2017 №350, 07.05.2018 №347, 19.09.2018 №892, 09.01.2019 №8, 13.05.2019 №362, 14.11.2019 №1022, 10.02.2020 №84, 14.07.2020 №512, 2.10.2020 №690 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган «Бөек Ватан сугышы ветераны» таныклыгын (таныклык дубликатын) бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1.2.1 пунктның икенче абзацында «блокадалы Ленинградта яшәүчегә» билгесе белән һәм» сүзләреннән соң «Камалган Севастопольдә яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затлар» сүзләрен өстәргә;

2.5 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасының дүртенче абзацында «блокадалы Ленинградта яшәүчегә» билгесе» сүзләреннән соң «, «Камалган Севастопольдә яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән гражданнар» өстәмә рәвештә «Камалган Севастопольдә яшәүче» билгесенә таныклык күчермәсен дә тапшыра» сүзләрен өстәргә.

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2014 елның 19 ноябрендәге 634 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 09.07.2015 №461, 09.11.2015 №821, 07.06.2016 №317, 20.07.2016 №420, 28.11.2016 №668, 27.02.2017 №104, 08.06.2017 №349, 28.05.2018 №401, 18.09.2018 №857, 04.02.2019 №77, 07.05.2019 №322, 10.09.2019 №689, 14.11.2019 №1021, 24.03.2020 №192, 13.07.2020 №502, 02.10.2020 №691боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында (алга таба – Регламент):

1 бүлекнең 1.2 пунктында:

4 пунктчада «блокадалы Ленинградта яшәүчегә» билгесе белән һәм» сүзләреннән соң «Камалган Севастопольдә яшәүче» билгесе белән бүләкләнгән затлар» сүзләрен өстәргә;

39 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«39) авыл җирлегендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче Татарстан Республикасы дәүләт мәгариф оешмаларының, муниципаль мәгариф оешмаларының педагогика хезмәткәрләре, әлеге мәгариф оешмаларының җитәкчеләре һәм аларның урынбасарлары, әлеге мәгариф оешмаларының структур бүлекчәләре җитәкчеләре һәм аларның урынбасарлары мәдәният, сәнгать һәм кинематография өлкәсе, социаль хезмәтләр дәүләт системасының социаль хезмәт күрсәтүче учреждениеләре хезмәткәрләре, шулай ук пенсиягә чыккан гражданнар, 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җиткән гражданнар, шулай ук 2018 елның 31 декабренә булган торышында «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән, авыл җирлегендә яши торган һәм Татарстан Республикасының авыл җирлегендә урнашкан Татарстан Республикасы мәгариф оешмаларында, Татарстан Республикасы мәдәният учреждениеләрендә, Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә кимендә 10 ел эшләгән аталган хезмәткәрләр исәбендәге гражданнар;»;

2 бүлектә:

2.4 пунктның «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасындагы өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы 32-35, 37-41 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләрнең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү бурычларны түләп бетергәнчегә кадәр, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать иткән көннән башлап 90 көннән артык булмаган чорга туктатылып тора.» (Әлеге Регламентның 1.2 пунктының 37-40 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләр өчен әлеге абзац таләбе 2021 елның 1 апреленнән гамәлдә була);

2.5 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Социаль түләүләр алу өчен федераль законнар нигезендә банкта яки башка кредит учреждениесендә ачылган счет реквизитларын күрсәтеп, субсидия-ташламалар бирү турында гариза. Гаризаның киңәш ителә торган рәвеше әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелде.

2. Күпфатирлы йортларда торак урыннарның милекчеләре өстәмә рәвештә аңа карата хокук Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында теркәлмәгән торак урынга хокук билгели торган документларның күчермәләрен дә тапшыра.

3. Әлеге Регламентның 1.2 пунктының 37-40 пунктчаларында күрсәтелгән затлар өстәмә рәвештә эш урыныннан субсидия-ташлама алу хокукы турында белешмә дә тапшыра.

4. Әлеге Регламентның 1.2 пунктының 41 пунктчасында күрсәтелгән затлар өстәмә рәвештә түбәндәгеләрне тапшыра:

чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән баланың тууын дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклык күчермәсе һәм аларның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе;

чит ил дәүләтенең компетентлы органнары тарафыннан бирелгән никахны дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклык күчермәсе һәм аларның нотариаль яктан расланган рус теленә тәрҗемәсе.

5. 2018 елның 31 декабренә «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган, ләкин 60 һәм 55 яшенә (тиешенчә ир-атлар һәм хатын-кызлар) җитмәгән хезмәт ветераннары, «Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре турында» Татарстан Республикасы Законы белән гамәлгә куелган Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән, 2018 елның 31 декабренә «Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнарда каралган пенсияне билгеләү шартларына туры килә торган затлар өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Пенсия фондының Татарстан Республикасы бүлегеннән үзләренең 2018 елның 31 декабренә федераль законнарда каралган пенсия билгеләү шартларына туры килүе турындагы белешмәне тапшыралар.

Документлар һәм белешмәләр мөрәҗәгать итүче тарафыннан тиешле оешмаларда – турыдан-туры, шул исәптән, мондый мөмкинлек булган очракта, электрон рәвештә алына.

Законлы вәкилләр (законнарда каралган очракларда) яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән затлар мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләтләрен раслый торган документны күрсәтә.

Документларның күчермәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, төп нөсхәләре белән бергә тапшырыла, алар төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге хезмәткәре тарафыннан таныклана.

Мөрәҗәгать итүче мөрәҗәгать иткәндә шәхес таныклаучы документ, банкта яисә башка кредит оешмасында ачылган шәхси счет реквизитларын, шулай ук, гамәлдәге законнарда каралган очракларда, мөрәҗәгать итүченең субсидия-ташлама алу хокукын раслаучы документны күрсәтә.

Дәүләт хезмәтеннән файдалану буенча гариза бланкын мөрәҗәгать итүче Үзәк бүлегенә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Гариза бланкының электрон рәвеше Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан кәгазьдә яисә почта аша хат итеп тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. Гаризаны почта аша җибәргәндә аңа теркәлә торган документларның күчермәләре (шәхесне таныклый торган документ күчермәсеннән кала) Россия Федерациясе законнары нигезендә таныкланган булырга тиеш.

Гариза һәм аңа теркәлә торган документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре, шул исәптән «Интернет» челтәре яки Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша да тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин. Зеленодольск шәһәрендә

яшәүчеләр өстәмә рәвештә Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәте инфоматлары аша гариза җибәрә ала, аларның адреслары Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр Порталында урнаштырылган.»;

2.6 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара багланыш каналлары буенча вәкаләтле органнардан белешмәләр алына:

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү хакында;

федераль законнар нигезендә айлык акчалата түләү алудан баш тарту турында;

даими яшәү урыны буенча законнар нигезендә торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларына хокуклы гражданин белән бергә теркәлгән гражданнар турында;

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында үзенә карата хокук теркәлмәгән торак урынга милекчелек хокукы турында;

инвалидлык билгеләү факты турында;

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычлар булуы (булмавы) турында;

төрләренең исемлеге 126 номерлы Нигезләмә кушымтасында күрсәтелгән физик затларның керемнәре турында (хезмәт ветераннарына субсидия-ташлама билгеләү өчен);

тууны дәүләт теркәвенә алу турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә субсидия-ташлама билгеләү өчен);

ата-ана хокукыннан мәхрүм итү, баланы тәрбиягә гаиләгә тапшыру турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә субсидия-ташлама билгеләү өчен);

өйләнешүне дәүләт теркәвенә алу турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә субсидия-ташлама билгеләү өчен);

аерылышуны дәүләт теркәвенә алу турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә субсидия-ташлама билгеләү өчен);

инвалидка (инвалид балага) айлык акчалата түләү билгеләү турында (инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә субсидия-ташлама билгеләү өчен);

әгәр мөрәҗәгать итүче 14 яшенә җитмәгән балигъ булмаган зат булса, законлы вәкил вәкаләтләрен раслау өчен опека (попечительлек) билгеләнүе турында (җирле үзидарә органнарында);

шәхси счетның иминият номеры турында;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булуы (булмавы) турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы 32-35, 37-41 пунктчаларында күрсәтелгән мөрә-

җәгать итүчеләргә субсидия-ташламалар билгеләү өчен) (Федераль салым хезмәтендә) (әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы 37-40 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләр өчен әлеге абзац таләбе 2021 елның 1 апреленнән гамәлдә була).

Мөрәҗәгать итүченең Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша мөрәҗәгатендә мөрәҗәгать итүче паспортының чынлыгын раслау турында белешмәләр ведомствоара хезмәттәшлек каналлары буенча өстәмә рәвештә алына.

Мөрәҗәгать итүче югарыда аталган белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы белән дә тапшырырга хокуклы.

Әлеге документлар мөрәҗәгать итүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан алынырга мөмкин, шул исәптән, мондый мөмкинлек булганда, электрон формада да, һәм әлеге Регламентның 2.5 пунктында каралган документларны тапшыру өчен әлеге Регламентта каралган тәртиптә тапшырылырга мөмкин.

Югарыда күрсәтелгән белешмәләрдән торучы документларның мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылмавы мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый.

Үзәк мөрәҗәгать итүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда аларны тапшыру яки гамәлгә ашыру күздә тотылмаган документларны һәм мәгълүматны тапшыруны яки гамәлләр башкаруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 6 өлешендә каралган документлардан тыш, шул исәптән мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәткән өчен түләү кертелүен раслый торган, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәтләрен күрсәтүче органнар, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнаша торган дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалары карамагында булган документлар һәм мәгълүмат тапшыруны;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән беренче мәртәбә баш тартканда булмавы һәм (яки) төгәл булмавы турында күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүмат тапшыруны.»;

2.8 пунктта «Стандартка карата таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы 32-35, 37-41 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләрдә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булуы дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигез булып тора (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 37-40 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләр өчен әлеге абзац таләбе 2021 елның 1 апреленнән гамәлдә була).

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

шушы Регламентның 1.2 пунктында күрсәтелмәгән затның мөрәҗәгать итүе;

әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы 32-40 пунктчаларында күрсәтелгән зат-

ларның Татарстан Республикасы законнарында яисә федераль законнарда билгеләнгән башка нигезләр буенча, 63-ТРЗ номерлы законның 9 статьясы һәм 251 номерлы тәртипнең 15 пункты таләпләрен исәпкә алып, социаль ярдәм чараларын алуы;

субсидия-ташламалар алу өчен дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылуы;

Әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы 32-35, 37-41 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләрдә Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча субсидия-ташлама билгеләү өчен мөрәҗәгать иткән көннән башлап 90 көн өчендә җайга салынмаган бурычлары булуы.» (Әлеге Регламентның 1.2 пунктының 37-40 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләр өчен әлеге абзац таләбе 2021 елның 1 апреленнән гамәлдә була);

3 бүлектә:

3.1.1 пунктның 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту), дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында карар әзерләү;»;

3.4.1 пунктның дүртенче абзацында «, 2013 елның 23 октябреннән соң туган» сүзләрен төшереп калдырырга;

3.4.2 пунктны киләсе редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Субсидия-ташлама билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар кабул итү өчен кирәкле белешмәләр Үзәк бүлегендә булмаганда, Үзәк бүлеге белгече электрон рәвештә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасы ярдәмендә түбәндәге белешмәләрне вәкаләтле органнардан сората:

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсиясе белән тәэмин итү турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү хакында;

федераль законнар нигезендә айлык акчалата түләү алудан баш тарту турында;

даими яшәү урыны буенча законнар нигезендә торак урын һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларына хокуклы гражданин белән бергә теркәлгән гражданнар турында;

Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында үзенә карата хокук теркәлмәгән торак урынга милекчелек хокукы турында;

инвалидлык билгеләү факты турында;

салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләнергә тиешле бурычлар булуы (булмавы) турында;

төрләренең исемлеге 126 номерлы Нигезләмә кушымтасында күрсәтелгән физик затларның керемнәре турында (хезмәт ветераннарына субсидия-ташламалар билгеләү өчен);

тууны дәүләт теркәвенә алу турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә субсидия-ташламалар билгеләү өчен);

ата-ана хокукыннан мәхрүм итү, баланы тәрбиягә гаиләгә тапшыру турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә субсидия-ташлама билгеләү өчен);

өйләнешүне дәүләт теркәвенә алу турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә субсидия-ташлама билгеләү өчен);

аерылышуны дәүләт теркәвенә алу турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 12 һәм 41 пунктларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә субсидия-ташлама билгеләү өчен);

инвалидка (инвалид балага) айлык акчалата түләү билгеләү турында (инвалидларга һәм инвалид балалары булган гаиләләргә субсидия-ташлама билгеләү өчен);

әгәр мөрәҗәгать итүче 14 яшенә җитмәгән балигъ булмаган зат булса, законлы вәкил вәкаләтләрен раслау өчен опека (попечительлек) билгеләнүе турында (җирле үзидарә органнарында);

шәхси счетның иминият номеры турында;

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булуы (булмавы) турында (әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы 32-35, 37-41 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләргә субсидия-ташлама билгеләү өчен) (Федераль салым хезмәтендә) (әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы 37-40 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләр өчен әлеге абзац таләбе 2021 елның 1 апреленнән гамәлдә була).

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: белешмәләр бирү турында рәсми мөрәҗәгатьләр.»;

3.5-3.6 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту), дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында карар әзерләү

3.5.1. Үзәк бүлеге белгече әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән, алынган белешмәләр һәм әлеге Регламентның 3.4.2 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара хезмәттәшлек органнарыннан законнарда билгеләнгән срокларда алынган, мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документлар нигезендә түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

мөрәҗәгать итүченең законлы вәкиле яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан вәкаләт бирелгән зат вәкаләтләрен тикшерү;

әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту нигезләре булу-булмавын тикшерә;

дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен кирәкле, әлеге Регламентның 2.8 пунктында каралган нигезләр булу-булмавын тикшерә;

әлеге Регламентка 3, 6 нчы кушымталар нигезендәге формалар буенча электрон рәвештә субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту) яисә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар проектын рәсмиләштерә;

субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту) яки дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карар проектын электрон рәвештә Үзәк бүлеге җитәкчесенә имза кую өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедуралар рәсми мөрәҗәгатьләргә җаваплар алынган көннән ике эш көне эчендә, әмма гаризаны теркәгәннән соң җиде эш көненнән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында яки электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында электрон рәвештәге карар проекты.

3.5.2. Үзәкнең бүлек җитәкчесе субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту) яки дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында электрон рәвештәге карар проектын карый һәм электрон санлы имза белән имзалап, Үзәк бүлеге белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура документларны субсидия-ташлама билгеләү турында (билгеләүдән баш тарту турында) карар проекты җибәрелгән көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында яки дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында электрон рәвештәге карар.

3.5.3. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында белдерү

Үзәкнең бүлек белгече дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан субсидия-ташлама билгеләү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресына язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга СМС-хәбәр җибәреп) хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында карарга кул куйганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү.

3.5.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне яңарту яки субсидия-ташлама билгеләүдән баш тарту турында карар кабул итү

3.5.4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү туктатылган вакыт эчендә әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы 32-35, 37-41 пунктчаларында күрсәтелгән затлар исәбендәге мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмавы турында белешмәләр алынса, яисә мөрәҗәгать итүче күрсәтелгән бурычны җайга салуны раслаучы документларны тапшырса, Үзәк бүлеге белгече: (әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы 37-40 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләр өчен әлеге абзац таләбе 2021 елның 1 апреленнән гамәлдә була)

әлеге Регламентка 6 нчы кушымта нигезендәге форма буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне яңарту турында карар проектын электрон рәвештә рәсмиләштерә;

әлеге Регламентка 3 нче кушымта нигезендә субсидия-ташлама билгеләү турында карар проектын рәсмиләштерә;

дәүләт хезмәте күрсәтүне яңарту һәм субсидия-ташлама билгеләү турындагы карар проектларын Үзәкнең бүлек җитәкчесенә имзалау өчен җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычның булмавы яисә мөрәҗәгать итүче тарафыннан бурычларны җайга салуны

раслый торган документлар тапшырылганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: дәүләт хезмәте күрсәтүне яңадан торгызу һәм субсидия-ташлама билгеләү турында карарлар проектлары.

3.5.4.2. Әлеге Регламентның 1.2 пунктындагы 32-35, 37-41 пунктчаларында күрсәтелгән затлар исәбендәге мөрәҗәгать итүченең субсидия-ташлама билгеләү турында гариза тапшырылган көннән башлап 90 көн узгач Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары җайга салынмаган очракта, Үзәк бүлеге белгече субсидия-ташлама билгеләүдән баш тарту турында карар проектын әзерли һәм Үзәк бүлекчәсе җитәкчесенә имзалау өчен җибәрә. (әлеге Регламентның 1.2 пунктының 37-40 пунктчаларында күрсәтелгән мөрәҗәгать итүчеләр өчен әлеге абзац таләбе 2021 елның 1 апреленнән гамәлдә була);

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура субсидия-ташлама билгеләү турында гариза биргән көннән соң 90 көн узгач, аннан соңгы бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: субсидия-ташлама билгеләүдән баш тарту турында карар проекты.

3.5.4.3. Үзәк бүлеге җитәкчесе дәүләт хезмәте күрсәтүне яңадан торгызу турында һәм субсидия-ташлама билгеләү турында карар проектларын яисә субсидия-ташлама билгеләүдән баш тарту турында карар проектын карый һәм электрон санлы имза белән имзалый һәм Үзәк бүлеге белгеченә җибәрә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура дәүләт хезмәте күрсәтүне яңадан торгызу турында һәм субсидия-ташлама билгеләү турындагы карар проектларына яисә субсидия-ташлама билгеләүдән баш тарту турындагы карар проектына кул куйганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Үзәк бүлеге җитәкчесе тарафыннан имзаланган дәүләт хезмәте күрсәтүне яңадан торгызу һәм субсидия-ташлама билгеләү яки субсидия-ташлама билгеләүдән баш тарту турында карарлар.

3.5.4.4. Үзәкнең бүлек белгече дәүләт хезмәте күрсәтүне яңартып җибәрү турында кабул ителгән карар турында мөрәҗәгать итүче тарафыннан субсидия-ташлама билгеләү турындагы гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресына язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга СМС-хәбәр җибәреп) хәбәр итә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура дәүләт хезмәте күрсәтүне яңарту турында карарга кул куйган көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне яңарту турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү.

3.6. Мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү

Үзәкнең бүлек белгече мөрәҗәгать итүчегә мөрәҗәгать итүче тарафыннан күрсәтелгән ысул белән (почта адресына язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга СМС-хәбәр җибәреп яисә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына юллау юлы белән) субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар җиткерә.

Әлеге пунктта билгеләнә торган процедура субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар кабул ителгән көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында кабул ителгән карар турында хәбәр итү, Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында карар җибәрү.»;

3.8 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Техник хатаны төзәтү әлеге Регламентка 5 нче кушымтаге форма буенча, дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турындагы документны яки мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак тапшырылган, техник хатасы булган документны (әгәр андый документлар бирелгән булса) теркәп, мөрәҗәгать итүче тарафыннан гариза тапшырылган очракта гамәлгә ашырыла.»;

3.8.1 пунктта:

өченче абзацта «үзгәртеп рәсмиләштерә» сүзләреннән алда «дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында карар проектын яки» сүзләрен өстәргә.

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар проектын яисә субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турындагы карар проектын электрон рәвештә Үзәк бүлеге җитәкчесенә имзалау өчен җибәрә.»;

алтынчы абзацта «үзгәртеп рәсмиләштерелгән» сүзләреннән соң «дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында карар проекты яки» сүзләрен өстәргә;

3.8.2 пунктта:

беренче абзацта «үзгәртеп рәсмиләштерелгән» сүзләреннән соң «дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында карар яки» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацта «үзгәртеп рәсмиләштерелгән» сүзләреннән соң «дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында карар яки» сүзләрен өстәргә;

3.8.3 пунктта:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.8.3. Үзәк бүлеге белгече мөрәҗәгать итүчегә гаризада күрсәтелгән ысул белән (почта адресына язмача формада, электрон почта адресы буенча электрон документ формасында, телефонга СМС-хәбәр җибәреп яисә Татарстан Республикасы Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетына юллау юлы белән) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар яки субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар турында хәбәр итә.»;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Процедураның нәтиҗәсе: мөрәҗәгать итүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында яисә субсидия-ташлама билгеләү (билгеләүдән баш тарту) турында үзгәртеп рәсмиләштерелгән карар турында хәбәр итү, үзгәртеп рәсмиләштерелгән карарны мөрәҗәгать итүчегә җибәрү.».

Регламентка 1 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

форма

Республика матди ярдәм (компенсация түләүләре) үзәге ДКУ №___ бүлегенә ______________________ муниципаль районында (шәһәр округында)

ГАРИЗА

«__» __________ 20__ ел.

Мин, ________________________________________________________________,
(мөрәҗәгать итүченең тулысынча фамилиясе, исеме, атасының исеме)
яши торган адрес:
______________________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең почта адресы, индексы, телефоны, электрон почта адресы)

| Шәхесне раслаучы документ исеме | Сериясе һәм (яки) номеры | Кем тарафын-нан бирелгән | Бирелгән датасы |
|---|---|---|---|
| | | | |

Эш итү нигезе ______________________________________________________
(мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтеннән файдаланучы зат мәнфәгатьләрендә эшләү вәкаләтен раслаучы документ реквизитлары)

Торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә субсидия-ташлама билгеләүне сорыйм
______________________________________________________________________
(дәүләт хезмәтеннән файдаланучының фамилиясе, исеме, атасының исеме)
Мөрәҗәгать итүченең хосусый шәхси счет номеры _____________
Түбәндәге документларны (белешмәләрне) тапшырам:

| | Документлар атамасы | Нөсхәләр саны |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

| | | |
|---|---|---|
| | | |

Билгеләнгән түләүләрне түбәндәгечә түләүне сорыйм:
счетка күчерү юлы белән

______________________________________________________________________
(дәүләт хезмәте алучы яисә аның законлы вәкиле тарафыннан законнарда билгеләнгән тәртиптә ачтырылган счет реквизитлары күрсәтелә)

почта бүлеге аша ______________________________________________
(дәүләт хезмәтеннән файдаланучының яисә аның законлы вәкиленең почтадан җибәрү реквизитлары күрсәтелә)

Тапшырылган белешмәләрнең дөреслеге, аларны үз эченә алган документларның дөреслеге өчен җаваплылык турында һәм торак урынга һәм коммуналь хезмәтләргә түләүдә субсидия түләүгә йогынты ясаучы шартларның үзгәрүе турында вакытында хәбәр итү бурычы турында нигезләмәләр белән таныштырылдым. Мөрәҗәгать итүче:___________________________________ _________ «__» _______ 20_ ел.
(Мөрәҗәгать итүченең Ф.И.А.) (имза)

Мәгълүмат алу, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү (дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту), дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору (яңарту) турында мәгълүмат алуга риза:

______________________________________________________________________
(почта адресы буенча хат белән, смс-хәбәр итеп, электр почта адресы буенча электрон почта белән)

«__»________ 20__ ел. Имза ______________

Хезмәт ветераннары өчен каралган социаль булышлык күрсәтү чараларын алуга хокук югалган очракта, ТР Министрлар Кабинетының 17.12.2004 №542 карары белән пенсионерлар өчен каралган юлда йөрүгә ай саен бирелә торган акчалата түләү алуга риза.
Мөрәҗәгать итүченең имзасы ____________________________
(хезмәттән файдаланучы булып хезмәт ветераны торган очракта тутырыла)

Яңа вакытка социаль ярдәм чараларын автомат рәвештә билгеләү белән килешәм.
Мөрәҗәгать итүченең имзасы ____________________________
(хезмәттән файдаланучы булып хезмәт ветераны торган очракта тутырыла)

